ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.06.2019 Алексеевск ш.т.б. № 263

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2018 елның 27 июлендәге 215 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 матдәсенә үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2018 елның 27 июлендәге 215 номерлы карарына яңа редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

- 3.3.3 пункты

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 матдәсендәге 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләр белән беррәттән планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен нигез булып система аша дәүләт торак күзәтчелеге органына, муниципаль торак контроле органына гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан мәгълүмат керү, мәгълүмат системасында дәүләт торак күзәтчелеге органы, муниципаль торак контроле органы тарафыннан күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда биналарның милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү, туктатып тору һәм чикләү кагыйдәләре таләпләрен бозу, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативын төзү

тәртибенә, торак милекчеләре ширкәте уставына, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативына карата таләпләрне һәм мондый ширкәт яки мондый кооператив уставына үзгәрешләр кертү тәртибенә, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан күпфатирлы йорт белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы (алга таба – идарәче оешма), оештыру-хокукый формасына яисә шәхси эшмәкәрнең хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик зат сайлап алу турында карар кабул итү тәртибенә карата таләпләрне бозу фактлары ачыклану, идарәче оешма белән, күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсен төзү максатларында, идарәче оешма белән күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү шартнамәсен төзү һәм (яки) эшләр башкару турында карар, Россия Федерациясе Торак кодексының 164 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән затлар белән күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм (яисә) ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү шартнамәләрен төзү турында карар, әлеге шартнамәләрнең шартларын раслау һәм аларны төзү тәртибе, күпфатирлы йортта гомуми милекне агымдагы һәм капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыру тәртибе, күпфатирлы йорттагы торак бинаны торак булмаган бинага күчерү тәртибенә, күпфатирлы йорттагы биналарны үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибенә карата таләпләрне бозу фактлары турында, идарәче оешма тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 162 статьясындагы 2 өлешендә каралган йөкләмәләрне бозу фактлары турында, коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексларын куллану өлкәсендә закон бозу фактлары турында, коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллануның билгеләнгән нормативы күләменең нигезсез булуы, коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативлары составына карата таләпләрне бозу, коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативларын билгеләү шартларын һәм ысулларын сакламау, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен бозу фактлары турында, наемга алынган йортларда социаль файдаланудагы торак урыннарны найм бирүчеләр һәм мондый йортларда торак урыннарын яллаучыларга, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наймлау шартнамәләрен һәм торак урыннарын наймлау шартнамәләрен төзүгә һәм үтәүгә карата мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, гражданнар тарафыннан системада мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата таләпләрне бозу фактлары турында карарлар нигез булып тора.

Дәүләт торак күзәтчелеге органы, муниципаль торак контроле органы тарафыннан (лицензия контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан җирле үзидарә вәкаләтле органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү очрагында) планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә чыгарылган планнан тыш тикшерү билгеләү турында Россия Федерациясе баш дәүләт торак инспекторының боерыгы (күрсәтмәсе) тора. Күрсәтелгән нигезләр буенча

планнан тыш тикшерү прокуратура органнары белән килештермичә һәм планнан тыш тикшерү үткәрү турында оешманың алдан хәбәрнамәсеннән башка үткәрелә».

2. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2018 елның 27 июлендәге 215 номерлы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 13 мартындагы 118 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары А. Н. Абакумовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыров**